Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Баганалысы авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре № 7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 19 ноябрендә 14.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Баганалысы авылы, Үзәк ур., 35а йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, I төркем инвалидларыннан тыш, 1000 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- вак таш салып чокырлы юлларны ремонтлау (сатып алу, китерү, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- урамнарны яктыртуны тоту (урам яктырткычларын энергияне саклаучы яктырткычларга алыштыру, килешү буенча түләү)

«ЯКЛЫ» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Татар Баганалысы
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Җәббаров